**№2** **26.10.2022 ел**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге гражданнары җыены**

# КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге составына керүче Иске Элмәле, Яңа Элмәле торак пунктларында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге Уставының 22 ст., Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 июнендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль район Советының 2018 елның 24 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Элмәле авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын уздыруга әзерлек тәртибе турында» гы нигезләмәне раслау турында» 94 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 132 номерлы карары нигезендә КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2023 елда муниципаль районның Яңа Элмәле авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк кешеләрдән, күп балалы аналардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- җәйге һәм кышкы чорда юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, кышкы чорда урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, элмә һәм тагылма җиһазлар сатып алуга, тракторчыга хезмәт күрсәтүгә түләү) Яңа Элмәле һәм Иске Элмәле торак пунктларында;
- Яңа Элмәле һәм Иске Элмәле авылларында урамнарны яктырту, монтажлау, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Яңа Элмәле торак пунктында купель яны территориясен төзекләндерү (яшелләндерү, киртәләү, бура урнаштыру) югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар алу;
- Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәйкәлен Иске Элмәле торак пунктында ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар алу;

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгы Мельников В.П.**